# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

унтугызынчы утырыш
**КАРАРЫ**

29 апрель 2022 ел **№ 125** Теләче ав.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге 124 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатлар, сайланулы вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 12 апрелендәге 124 номерлы карары белән расланган 1 номерлы кушымтага (24.08.2018 № 136, 20.11.2019 № 209 09.10.2020 № 9, 12.11.2021 № 86 карар редакциясендә) түбәндәге эчтәлектә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатлар, сайланулы вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәгә 1 номерлы кушымта

## Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү тәртибе

1. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи окладка айлык процентлы өстәмәне түләү тәртибе

«Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы Карарыннан чыгып билгеләнә.

2. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи окладка айлык процент өстәмәне түләү күләме «Дәүләт серен саклау буенча гражданнарга һәм дәүләт серләрен яклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарында күрсәтелгән процент өстәмәләре нисбәтеннән чыгып билгеләнә.

Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен айлык процент өстәмәләре күләменең нисбәте

| Айлык процентлы өстәмә | Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләү өчен өстәмәләр күләме (вазыйфаи окладка карата %ларда) |
|---|---|
| «Аеруча мөһим» серлелек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен | 50-75 |
| Серлелек дәрәҗәсе булган «бөтенләй яшерен» мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 30-50 |
| Тикшерү чараларын үткәргәндә рөхсәт кәгазен рәсмиләштергәндә «яшерен» яшеренлек дәрәҗәсе булган белешмәләр белән эшләгән өчен, | 10-15 |
| тикшерү чараларын үткәрмичә | 5-10 |
| Дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен: | |
| 1 елдан 5 елга кадәр | 10 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 15 |
| 10 елдан һәм югарырак | 20 |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Теләче муниципаль районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов